УДК 792.09

***А. Воронин***

# М.Н. ЕРМОЛОВА ИСЕМЕНДӘГЕ МӘСКӘҮ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ ДИАС ВӘЛИЕВҺӘМ АЛЕКСАНДР ВАМПИЛОВ ДЕБЮТЫ

В статье предпринята попытка сопоставления пьес Д. Валеева и А. Вампилова. Диас Назихович Валеев (1938–2010) в Советском Союзе был самым известным драматургом из Казани. Начиная с 1972 г. его пьесы шли в Москве, Ташкенте и других городах страны. Наибольший успех выпал на долю драмы «Дарю тебе жизнь», которую впервые поставили в Московском драматическом театре имени М.Н. Ермоловой к 50-летию образования СССР. Московский дебют Диаса Валеева совпал с дебютом другого драматурга, Александра Вампилова.

**Ключевые слова:** Диас Валеев, Александр Вампилов, драматургия Татарстана, Московский драматический театр им. М.Н. Ермоловой.

Вәлиев Диас Назыйх улы (1938–2010) Советлар Союзы вакытында Казанның иң күренекле драматургы санала. 1972 елдан башлап, аның пьесалары Мәскәүдә, Ташкентта һәм тагын илнең иллеләп шәһәре сәхнәләрендә куела. Иң югары уңыш яулаган драмасы беренче мәртәбә СССР төзелүнең 50 еллыгы уңае белән М.Н. Ермолова исемендәге Мәскәү драма театрында сәхнәләштерелә, соңрак авторга бу хезмәте өчен ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1976) бирелә. Вәлиев өч тапкыр милли драматургия өлкәсендәге Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз конкурслары лауреаты була. Диас Вәлиевнең Мәскәү дебюты аның коллегасы драматург Александр Вампилов дебюты белән бер вакытка туры килә. А. Вампилов белән аның туган җире Иркутскида бик хаклы горурланалар, җирле яшь тамашачылар театры Александр Вампилов исемен йөртә, шунда ук аның музее да оештырылган... Иң мөһиме, Вампилов пьесаларын күп театрлар кабат-кабат сәхнәләштерәләр. Ә татар драматургын бөтенләй диярлек оныттылар... Бу һич кенә дә урынлы түгел. Әлеге ике драматург пьесаларын янәшә куеп, аларга кыскача тукталып үтик.

1

Диас Вәлиев белән Александр Вампилов драматургиясен әдәби чагыштыру идеясенең бу ике авторның тәүге пьесаларындагы башлангыч репликалар белән танышкач ук бәхәссезлеге ачыклана. Әйтик, Диас Вәлиевнең «Сквозь поражение» драмасы кичен ике төп геройның тукталышта, көтмәгәндә очрашулары белән башлана.

«С а л и х. Куда вам надо идти сейчас? Туда? Давайте лучше бродить сегодня там, где никогда не бываем. Сейчас восемь часов. Когда стрелка дойдет до двенадцати – разойдемся. Где бы ни были. На любом перекрестке.

Дина. Странно… Это прием у вас такой?»

Диас Валиев геройлары кышын трамвай тукталышында очрашса, Вампиловныкылар җәй көне автобус тукталышында, Таня афиша укып торганда очрашалар.

«Колесов. Девушка, куда вы едете, если не секрет?.. (У афиши). В кино?.. Нет? Ну, значит, на концерт… Тоже нет?.. Куда же вы собрались? Неужели в театр?.. Все ясно. Куда – вы этого сами еще не знаете. А раз так, то идемте со мной.

Таня. Пригласите кого-нибудь другого… И вообще у меня нет времени с вами разговаривать.

Колесов. Это неправда… Вы сколько раз прочли афиши? Скажите честно.

Таня (не сразу). Три. Ну и что?

Колесов. Видите, вам скучно.

Таня (пожала плечами). Просто я смотрю, куда завтра пойти.

Колесов. А сегодня? Куда вы хотите? На танцы? На концерт? На массовое гуляние?

Таня. Все это завтра. Почитайте. А в парке – через неделю.

Колесов. Чепуха! Мы откроем все это сегодня… На первый случай я приглашаю вас на свадьбу».

Танышып китү өчен яхшы башлангыч – Вампилов герое һич белмәгән кызны шунда ук туйга чакыра. Диас Вәлиев исә яшь парны бөтенләй еракка – Җир шары тирәли йөрергә җибәрә, җитмәсә, сәгать телләре һаман саен артка күчерелә тора. 60 нчы еллар модасы нигезендә гадәти булмаган мөнәсәбәт һәм сәер гадәтләр белән кызны гаҗәпләндерү таләп ителә. Вампиловта туй күренеше комедиягә әйләнә, ә Салихның туган көне (Вәлиевта) драмага әверелә. Шушы эпизодтан соң, «Сквозь порожение», «Прощание в июне» әсәренә түгел, «Утиная охота»га (Вампилов) аваздашлана.

Вампилов – Вәлиев янәшәлеге әсәрләрнең төп геройлары Салих белән Зилов образларында күбрәк чагыла, аларны ватан драматургиясендә барлыкка килә башлаган «торгынлык чоры геройлары» үрнәге дип санарга була. Утыз яшен тутырган, хатын-кыз мәсьәләсендә һәм гомумән тормышта өметен җуйган егетләр уңышсызлыкларында, башкаларны, таркалып баручы системаны түгел, ә үзләрен гаепliләр. Бу юнәлештә Вампилов белән Вәлиев, асылда, башлап юл салучылар. Драматургиядә моңа охшаш геройларны Вампиловтан соң, 70 нче еллар ахырында килеп туган «яңа дулкын» авторлары – Виктор Славин («Взрослая дочь молодого человека»дагы Бэмс һәм «Серсо»дагы Петушок. Анатолий Васильев постановкаларында бу образларны Альберт Филозов гәүдәләндерә), Александр Галин («Восточная труба»), Людмила Петрушевская («Уроки музыки»дагы Коля Козлов) һәм Мәскәүнең Алексей Арбузов студиясенә караган башка авторлар иҗат итә.

Салихның да, Зиловның да әтиләре белән мөнәсәбәтләре катлаулы. Локман Самматов заводлар төзи, ә аның уллары, тәрби-

ягә алган әтиләренең исеменнән файдаланып, җылы урыннарга урнашалар. Виктор Зиловның да әтисе югары урындагы җитәкче булган, бу аның улының «папашка – персональный пенсионер» дип ычкындырган сүзеннән аңлашыла. Әмма Виктор, инженер белеменә ия булса да, Техник мәгълүматлар үзәгендә генә эшли, һәм, эти номенклатура кысаларында калган булса, югарырак урнаша алган булыр идем, дип уйлый.

«Сквозь поражение» һәм «Утиная охота» драмаларындагы сюжет янәшәлеге ресторанда барган сәхнә күренешләре вакытында үзенең кульминацион ноктасына җитә. Вампиловның Виктор Зиловы эчеп исерә һәм анда чакырылганнарның чын йөзен ачарга омтыла, нәтиҗәдә официант Дима аның чыраена берне кундыра. Ә иртән аның торган җиренә «Безвременно сгоревшему на работе Виктору Зилову» дип язылган венок китереп куялар («...Пошутили сволочи») Салих Самматов ресторанда көтмәгәндә-уйламаганда Динаны очрата, ул аны инде күп еллар күрмәгән була. Дина үз ирен көтеп утыра... Ә ире, килгәч, чактан гына Салихның йөзенә сукмый кала. Анда эчеп исергән Салих икенче көнне иртән официантка ятагында уяна («...Все мужики – сволочи»).

2

Диас Вәлиевның «Суд совести» («Охота умножению») пьессасы, Аяз Гыйләҗев тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, «Намус хөкеме» дигән исем белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелгән. Ә «Дарю тебе жизнь» әсәрен В.И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры сәхнәләштерергә алына (спектакльнең премьерасы, автор үзе тәкъдим иткәнчә, «Продолжение» исеме белән 1972 елда була).

Александр Вампилов, Мәскәү театры премьераларына кадәр, туган җирендә – Иркутск яшь тамашачылар театрында (әйтеп үтелгәнчә, ул театр хәзер Вампилов исемен йөртә) куелган спектакльләренең («Старший сын») репетицияләрендә катнаша. К.С. Станиславский исемендәге Мәскәү драма театрында бу ике авторның әсәрләрен баш режиссер Владимир Андреев сәхнәләштерергә уйлый. Әмма театрларның репертуар планнары югары органнар тарафыннан раслана (ә андагы кайберәүләргә Вампилов комедияләре бөтенләй ошамый).

Ермоловалылар шул вакытта, пресса аша, баш режиссерның яшь татар драматургы Диас Вәлиев әсәрен («пьеса о Камазе») сәхнәләштетергә җыенуы турында хәбәр итәләр. Премьера СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән әзерләнә. Ә Вампиловның «Старший сын» комедиясен режиссер Геннадий Косюков сәхнәгә чыгарырга репетицияләр алып бара. Әмма беренче итеп Вәлиев пьесасы куелачагы аңлашыла.

Икенче яктан, баш режиссерны да аңларга була. Партия җитәкчелеге җитештерү тармаклары эшчәнлеген яктырткан пьесаларның сәхнәләштерелүен таләп итә, ә аңа КАМАЗ төзелеше башлану белән рухланып

язылган «Дарю тебе жизнь» һәрьяклап туры килә. Вампилов пьесалары исә «вак темалар» категориясе белән бара. Брежнев заманында мондый бәяләмә бик түбән санала.

Бу факт, театр тарихчыларын гына түгел, башкаларны да кызыксындырырга мөмкин: Вампилов һәм Вәлиев дебютлары Мәскәүнең бер үк сәхнәсендә бер үк диярлек вакытта бара. Моңа ирешү өчен Александр Вампиловның кыска гына бөтен гомере китә. Диас Вәлиевка башкала уңышына ирешү, үзенең туган ягы Казанда танылуга караганда, җиңелрәк була (аның бу әйтеп үтелгән пьесасы анда берничә атнага соңрак куела).

3

Александр Вампилов белән Диас Вәлиевны М.Н. Ермолова исемендәге Мәскәү театрының әдәби бүлек мөдире Елена Леонидовна Якушкина таныштыра. Зирәк фикерле, зыялы, киң эрудицияле Вампилов Вәлиевта уңай тәэсир калдыра. Гомеренең соңгы көннәре якынлашып килгәндә Диас Вәлиев Вампиловның Ермолова театрының әдәби бүлегендә машинкада басылган кульъязмасы белән танышуы, аның «Старший сын» пьесасының аеруча уңышлы булуы турында исенә төшереп, сөйләп утырды. Әмма элегрәк миңа Диас Назыйх улыннан бу авторның «Утина охота» әсәренә, гомумән аның башка геройларына карата тәнкыйди фикерләр, аларның «бик сай, соры, күңелсез» булуы хакында да ишетергә туры килгән иде. Диас Вәлиевка Вампилов драматургиясендә характерларның масштаблылыгы, дәртлелек җитми.

Александр Вампилов А.М. Горький исемендәге Әдәбият институтында Югары әдәби курсларда (Виктор Сергеевич Розов һәм Инна Люциановна Вишневскаяның иҗади семинарларында) белем ала.

Күрәсең, аның әдәбият институты хакында сөйләүләре Диаска да үз белемен күтәрүне дәвам итәргә кирәклеген искәртә. Биш елдан соң ул М. Горький исем. Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Вәлиев беренче пьесасын язганда, Вампилов инде үзенең барлык пьесаларын да иҗат итеп өлгергән була (бу аның С. Якушкина белән язышкан хатларыннан аңлашыла. «Новый мир», № 9, 1987 ел). Ул әле аларның һәркайсын берничәшәр кат эшли. Шуңа күрә аның башлап язган «Прощание в июне» комедиясе стилистика ягыннан соңгы «Прошлым летом в Чулимске» драмасыннан бер ягы белән дә аерылмый. Ә инде аның «Утиная охота» пьессасындагы тематик яңгыраш һәм драматик чагылыш аның барлык әсәрләрендә дә урын ала, һәм бу сыйфатлар Александр Вампиловның барысы биш пьесадан торган драматургиясен гаҗәеп бөтенлекле һәм җитлеккән хезмәтләр сафына күтәрә. Бәлки шуңа да Якушкина Сашаны «старший сын» дип кабул итә, ә Диасны ул, «младший сын» дип, хәтта ныграк та ярата.

Елена Леонидовна Вампилов пьессалары өстендә авторның

үзе белән бергәләп күп эшли. Якушкинаның төзәтергә һәм редакцияләргә осталыгын Диас Вәлиев тиздән үзе әсәрләре аша да аңлый. Башта алар «Сквозь поражение» өстендә эшлиләр, аннан «Охота к умножению»не эшкәртәләр. Иң нык төзәтелгәне «Дарю тебе жизнь» була.

4

Вампилов белән Вәлиев иҗади омтылышлары белән генә түгел, тышкы яктан да охшашлар: икесе дә бөдрәләнеп торган кара чәчле, кара һәм монголларга хас кысыграк күзле. Мәскәүлеләр өчен алар игезәк туганнар булып тоелырга да мөмкин, җитмәсә, яшьләре дә бер чама (Вампилов Вәлиевтан 9 ай да 10 көнгә генә зуррак). Икесе дә урта буйлы, артык таза да түгел.

Югары әдәби курсларда укып йөрүләре дә Вампилов белән Вәлиев биографиясендәге бердәнбер охшашлык кына түгел. Алар икесе дә провинциядә туганнар.

Иркутск өлкәсенең Вампилов туган Кутулик (бурятчага «чокыр» дип тәрҗемә ителә) соңрак район үзәгенә әйләнә. Диас Вәлиев туган Казанбаш (беренче өлеше «казан»; русчасы – котел, котловина. Бу сүзне дә «чокыр», сөзәк чокыр дип тәрҗемә итәргә була) авылы Татарстанның Арча районында.

Икесе дә балачактан ук әдәбиятка тартылалар. Кутулик мәктәбе директоры Валентин Никитич Вампилов (ялган донос буенча) кулга алынганчы югары сыйныфларда рус теле һәм әдәбияты укыта, һәм өченче улына исемне дә Пушкин хөрмәтенә Александр дип куша («рус поэзиясе кояшы»ның үлгән көнен 1937 елда зурлап билгеләп узалар). Әтиләрен атып үтергәннән соң да (ул 1957 елда гына реабилитацияләнә) аларның өйләрендә китаплар күп була. Әниләре үзе математик булса да балаларын рус классикасына кечкенәдән тарта.

Диас Вәлиевка килгәндә, аның әнисе күренекле татар язучысы Гадел Кутуйның бертуганы була. Ә әтисе – партия хезмәткәре – улы туганда шулай ук репрессияләнгән була. Саша да, Диас та яшерен рәвештә әтиләрен көтәләр, кешеләрнең үзләренә кырын каравын авыр кичерәләр... Вампиловка да, Вәлиевка да мәктәптән соң университетка керүдә (гаепсез әтиләрнең гаепсез балаларына каршылыклар булмый. Шуны да әйтергә кирәк: Себердәге Иркутскиның даны һич кенә дә Идел буе Казаныныкыннан ким булмый. Егетләрнең икесенең дә яшьлеге Хрущев «җепшеклеге» чорына туры килә, университет яшьләре яңа омтылышлар, яңа исемнәр белән рухланып гөр килә. Булачак драматурглар университет тормышының үзәгендә кайный. Икесе дә анда уку елларында хикәяләр яза башлый һәм үз шәһәрләрендәге иң җанлы әдәби берләшмәләргә йөри.

Минемчә, Александр Вампилов дусларыннан аеруча уңа. Иркутскиның әдәби түгәрәкләренә ул елларда Валентин Распутин, Вячеслав Шугаев, Марк Сергеев кебек алда зур танылу яулаячак язучылар йөри. Алар соңыннан да күп еллар бер-берсе белән араларын өзмиләр, бергә Байкалда

булалар, анда җәй көннәрендә аерым өй алып, әдәби коммуна оештыралар, язалар, аны бер-берсенә укыйлар, иҗатлары хакында фикер алышалар.

Дөрес, Диас Вәлиев та яхшы төркемгә эләгә – анда шагыйрьләр Юрий Макаров, Вил Мостафин, Николай Беляев була. Бу шагыйрьләр Иркутскидагы кебек «көчле төркем» буларак танылa да алмагандыр, чөнки алар, себерлеләр кебек, бердәм, бер-берсенә ярдәм итәргә омтылып тормыйлар. Хәер, провинция шәһәрләрендәге язучылар даирәсенә һәрчак аерымлану хас (хәзер ул бөтенләй чиктән тыш дәрәҗәдә). Мөгаен, башлап язучыларның үзара дуслык шартларында иҗат итүе, бер-берсен күтәрергә тырышуы аерылып торган әдәби төркемнең башкалада түгел, ә әллә кайдагы Иркутск шәһәрендә оешуы ярты гасырга бер була торган очрактыр. Алар, араларындагы иң зур танылу алачак Валентин Распутин кебек, «авыл гыйбадлары» булмый, аларны әдәби омтылыш, Әдәбиятның үзенә мәхәббәте берләштерә.

Вампилов белән Вәлиевның әдәбиятка юлы журналистикадан башлана. Һәм шунысы да характерлы – алар икесе дә яшьләр газетасында эшлиләр. Хәзер генә ул һәр шәһәрдә дистәләгән исемдәге газета һәм журналлар чыгарыла, ә совет чорында һәр нәрсә лимитлаштырылган иде. Әйтик, өлкә (Иркутск) һәм республика (Татарстан, Казан) үзәкләрендә бер партия һәм бер – комсомол газетасы чыгарылды. Аерым очракларда «кечке» басмалар рөхсәт ителде, алар, нигездә КПССның өлкә комитеты басма органы буларак һәм, чыннан да, кичке якта басылды (хәзерге мондый ваклыклар онытылды, «кичке» дип аталганнары да иртән басылып чыга). Димәк, ул елларда, эре заводлар каршында оештырылган күп тиражлы басмаларны санамаганда, каләм тирбәтүче провинциалларга сайланып тору мөмкинлеге юк иде. Андый шартларда яшьләр газетасы бик үк кулай басма булмый, әмма практик яктан алар иҗади планда иң җанлы һәм иң популяр редакция саналалар.

Журналист буларак бу ике автор да хәзер онытылып бара торган очерк жанры өстендә күп эшлиләр. Һәм алар икесе дә зур комсомол төзелешләрен яктыртуда юл салучылар булдылар. Иң мөһим төзлешләрдән Вампилов өчен – Усть-Илим ГЭСы (Ангарада беренче плотина аеруча зур әһәмияткә ия була, аның хакында Евгений Евтушенконың «Братская ГЭС» поэмасы языла. Вампилов ул чакта яшь була әле), ә Вәлиев өчен Яр Чаллыдагы Кама автомобиль заводы санала. Диас Назыйх улы 1969 елның декабрендә автошәһәр төзелеше башлану турында СССРда беренче булып хәбәр җиткергән язмасы хакында һәрчак зур горурлану белән искә ала иде. Ул чакта заводның рәсми атамасы да билгеле булмый, күпмедер дәрәҗәдә гарәпчәрәк яңгыраган «КАМАЗ» аббревиатурасын әле беркем дә ишетмәгән була.

5

Вәлиев һәм Вампилов пьесаларын чагыштырганда аларның тышкы янәшәлекләреннән үк ми-

салларны күпләп китерергә мөмкин. «Сквозь поражение» белән «Утиная охота»ны чагыштыру белән генә чикләнеп калу дөрес булмаячак. Җентеклэбрэк күзәткәндә «Охота к умножению» белән «Прошлым летом в Чулимске» пьесаларында да уртаклыклар шактый. Бу ике әсәрнең дә геройлары тикшерүчеләр («следователи») булып эшлиләр. «Пророк и черт»ның баш герое һәм «Двадцать минут с чертом»дагы Хомутовны да күп кенә сыйфатлар бәйли. Мондый мисалларны күпләп китерергә була.

Авторларның соңгы пьесаларында уртаклыклар аеруча күзгә ташлана. Диас Вәлиев үзенең «Карликовый буйвол» әсәрен триллер жанры итеп билгеләсә, А. Вампилов язылып бетмәгән «Несравненный Наконечников»ын водевиль (көлкеле пьеса) дип атый. Шуңа да карамастан ике фантасмагориянең дә фарс нигезе ап-ачык. Чагыштырып тасвирланган ике авторның да бу пьесаларын язу ирегe ул әсәрләрнең иң яхшы иҗади хезмәт булуын раслый.

Ни кызганыч, «Наконечников» язылып бетмичә кала, А. Вампилов үзенең 35 еллыгы алдыннан һәлак була. Ә Вәлиевның «Буйвол»ы сәхнәгә күтәрелә алмый, чөнки анда сурәтләнгән ил юкка чыга, таркала. Ә «яңа» Россия драматургиядә үзенә яңа кумирлар сайлый.

***Воронин Александр Геннадьевич,***
*Язучы, драматург, театр тарихчысы, Россия язучылар берлегенең Татарстан бүлеге Казан оешмасы рәисе*